ГЛАВА КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Вахитова, д.1а, с. Новый Кумазан, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ
Вахитов ур., 1а нче йорт, Яңа Комазан авылы, Мамадыш районы, 422151

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

21.10.2020 г. № 11

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Иске Черкас торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек Ерыкса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Иске Черкас авылы, Солнечная урамы, 5а йорты янында 2020 елның 13нче ноябрендә сәгать 11.00 дә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Иске Черкас торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлегенең Иске Черкас торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
-Солнечная урамындагы юлларны вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю);
урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, алмаштыру;
-юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек Ерыкса авыл җирлеге башкарма комитетына Иске Черкасторак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көек Ерыкса авыл җирлеге башлыгы: Ф.Р.Шәйхетдинов